Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авыл Советы

КАРАРЫ

04 сентябрь 2020 ел № 133

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2020 елның 03 мартындагы «Әлмәт муниципаль районы Клементейкино җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында»гы 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 07 июлендәге 564 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифасында тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифасында тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елның 20 июлендәге 09/13-09/3471 номерлы хатын карап

Клементейкино авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2020 елның 03 мартындагы 122 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл җирлегенең пенсиягә чыгу уңаеннан муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында Нигезләмә турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитеты (алга таба - җирлек башкарма комитеты) тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү көненә кадәр 30 календарь көне кала бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (алга таба - Финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документларны тапшыра:

- муниципаль хезмәткәрнең айлык хезмәт хакы күләме турында белешмә;

- муниципаль хезмəттəге эш стажы турында, җитəкче һəм кадрлар хезмəте тарафыннан расланган белешмə;

- Россия Федерациясе Хезмəт кодексының 66.1 статьясында билгелəнгəн тəртиптə алынган хезмəт китабы күчермəсен һəм (яисə) хезмəт эшчəнлеге турында белешмəлəр;

- кадрлар хезмəте тарафыннан расланган хəрби билет күчермəсен (элеге документ муниципаль хезмəткəрдə булганда);

- сыйныф чинын бирү, муниципаль хезмəткəрнең вазыйфаи окладка керə торган акчалата өстəмəлəр билгелəү турындагы карардан өземтəлəр;

- җирлек Башкарма комитеты җитəкчесе һəм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган форма (кушымта) буенча башкарылган бер тапкыр бүлəклəүнең исəп-хисабы;

- муниципаль хезмəткəрнең эш стажын билгелəү өчен законнар нигезендə кирəкле башка документлар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Әлмəт районы Клементейкино авылы, Центральная урамы, 38А йорт; Татарстан Республикасы, Әлмəт районы, Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 38А йорт; Татарстан Республикасы,Әлмəт районы, Яңа Чишмə авылы, Гафиятуллин урамы, 3А йорт территориясендə урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итəргə, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мəгълүматының рəсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һəм Әлмəт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтəрендə урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтəлешен тикшерүдə тотуны Клементейкино авыл җирлеге Башлыгына йөклəргə.

Клементейкино авыл
җирлеге Башлыгы Л.Э. Языков